# Г. Ибраһимов хезмәтләрендә татар тел белеме терминологиясе

Казан федераль (Идел буе)университетның
тәрҗемә белеме һәм сөйләм коммуникациясе
кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты
Шәмсетдинова Рәсимә Равил кызы

Г.Ибраһимов татар теленең иҗтимагый функциясен киңәйтү, фәннең һәр тармагы өчен атамалар – терминнар булдыруны ул үз чорының иң мөһим мәсьәләләреннән саный. Ул терминология өлкәсендә түбәндәге нигезләмәгә нигезләнә: “ аерым бер милләт булып яшәү әмәле булган халыклар үз телләрендә фән вөҗүдкә китерергә тиешлеләр. Боңа ирешү өчен, фәнни истиляхны – булдыра алган чаклы – үз телләрендә ясап, җитмәгән, ләкин зарур булган урынларда гыйлемдә остаз итеп торкан икенче милләтләрдәге истияхларны алырга мәҗбүр булалар. Бу һәм һәр халкта шулай була килә” (Ибраһимов . Истиляхлар һәйәтендән)

Г.Ибраһимов татар теленең фән өлкәсендә үз урынын алу шактый катлаулы һәм акрын бара торган юнәлешләрнең берсе икәнлеген яхшы аңлый. Үзенең “Татар сарыфы” һәм “Татар нәхүе” китапларында Г.Ибраһимов тел белеме терминнарын мөмкин кадәр татар теленең үз чаралары ярдәмендә ясарга тырыша. Ул яңа терминны телгә булган сүзгә яңа мәгънә биреп, яки телнең сүз ясый алу мөмкинлекләреннән файдаланып кертеп җибәрергә мөмкин дип саный.

Галимнең лингвистика өлкәсенә караган хезмәтләрендә татар теленең үз чараларыннан файдаланып ясалган терминнар шактый актив кулланыла һәм алар төрле ысулларга нигезләнгән. Шулар арасында иң активы – әзер сүзне терминлаштыру юлы белән ясалган терминнар: *боерык , ияртү, сөйләүче (I), сүз, тамыр, тыңлаучы (II зат), урын, үзгәреш, үзәк (сүзнең тамыры), ярашу*.

Галим кушымчалау ысулы белән терминнар ясауның продуктив булуын ассызыклый һәм шул ысул белән ясалган уңышлы гына терминнар тәкъдим итә, аларның шактый өлеше тел белеменә кереп китә, урнашып кала. Мәсәлән: *аергыч, аерылмыш, аталма(атама), барлык-юклык, бәйлек, искәрмә, саналмыш, сөйләгеч (I зат) тезем, теркәләгеч (изафә бәйләнешендә булган сүзләрнең беренчесе), теркәләнмеш (изафә бәйләнешендә булган сүзләрнең икенчесе), төрдәш (сыйфат фигыль), эндәшелгеч (II зат), ярдәмлек, ясалыш*.

*Аерым алмаш* (аерым язылa торган алмашлыклар), *билгеләү алмашлары, бүлем ярдәмлекләре* (бүлүче теркәгечләр), *җыю ярдәмлекләре* (җыючы теркәгечләр), *зат алмашлары* (зат алмашлыклары), *иярчен кисәкләр, иярчен сүзләр* (ярдәмлек сүз төркемнәре), *кереш сүз, каеру ярдәмлекләре* (каршы куючы теркәгечләр), *охшату ярдәмлекләре* (чагыштыру мәгънәсен белдерүче бәйлекләр), кебек бүгенге дәреслекләрдә кулланыла торган, лингвистик *төп сан, чама саны* терминнар-сүзтезмәләр дә Г. Ибраһимов тарафыннан кертеп җибәрелә.

Г. Ибраһимов үзенә кадәр язылган фәнни хезмәтләрнең теленә дә гаять игътибарлы, аларны өйрәнеп, уңышлы дип сайлаган терминнарны үзенең фәнни хезмәтләрендә куллана, мисал итеп *берлек-күплек* (Ш. Иманаев), *иҗек* (К.Насыйри), *тынышлар* (М.Өметбаев), *ымлык* (Г. Нугайбәк), *сан, өлеш саны, бүлем саны* (Г.Фәезханов), *сүз төре* (Һ. Масуди) һ.б. ларны китерергә мөмкин.

Дөрес, татар теленең үз мөмкинлекләренә нигезләнеп ясалган терминнарның бүгенге көндә телдә урнашып китүләре төрлечә була. Бер төркем терминнар галим кертеп җибәргән хәлдә телебезгә кереп китәләр һәм актив кулланылып киләләр, мәсәлән: *искәрмә, кереш сүз, аваз, аергыч, барлык-юклык, сан, саналмыш, сүз, тамыр* һ.б. Кайбер терминнар бүгенге телдә беркадәр морфологик үзгәрешләр кичергән хәлдә кулланылалар: *зат алмашлары, күргәзү алмашлары, аталма, җыю ярдәмлекләре, тынышлар,*

*эндәш* һ.б. Терминнарның бер өлеше тел гыйлемендәге күренешләргә караш үзгәрү барышында, алар белдергән төшенчәләр юкка чыгу сәбәпле, пассивлашып, кулланылыштан төшеп калган: *сүз җилеме, юлдаш, кире өтер, тоташ алмаш, аерым алмаш, юлдаш сүзләр, явыз теләк* һ.б.; кайберләре урынына хәзерге тел белемендә башка терминнар кулланыла: *каеру ярдәмлекләре, иярчен сүзләр, төрдәш, эндәшелгеч* һ.б.

Галим татар телендәге алынма терминнарга карата да үз мөнәсәбәтен белдерә. Телгә кереп урнашкан һәм күп еллар дәвамында кулланылышта йөргән гарәп һәм фарсы чыгышлы алынма терминнар Г.Ибраһимовның тел гыйлеменә караган хезмәтләрендә мөһим урын алып торалар, шундыйлардан *изафә, җөмлә, замир* (алмашлык), *имля, нәхү, истилях, назария, сарыф, шивә, асыл, вакыт, заман, исем, мәгънә, сыйфат, фигыль, хәреф* һ.б. Бу терминнарның кайберләре хәзерге вакытта традицион гарәп тел белемендә кулланыла, ә кайберләре бераз үзгәртелеп, ләкин галим биргән эчке формасы, төшенчә белән атама арасында бәйләнеш табигате сакланган хәлдә кулланылышта йөрүләре күзәтелә. Шулай ук галимнең тел белеменә караган хезмәтләрендә гарәп-фарсы алынмаларын нигез итеп, татар теленең үз чаралары ярдәмендә төзелгән катнаш составлы яңа төр, нигездә, ике составлы терминнар булу күзәтелә: *исемлек галәмәтләре, сыйфатлык галәмәтләре, фигыльлек галәмәтләре, хәзерге заман, гамәлдәш бабы, хәзерге хәл, теләк бабы, төп исем, ялгыз исем, ким җөмлә, тавыш хәреф* һ.б. Мондый төр катнаш терминнарда алынма сүзләр күпчелек очракта ыру төшенчәләрне , ә татар теленең үз сүзләре төр төшенчәләрне белдерүләрен дә билгеләп китергә кирәк. Ыру төшенчә белдергән терминнарның, гадәттә, күпчелек телләр өчен уртак булган универсаль категорияләрне белдерүләрен исәпкә алсак, Г.Ибраһимовның терминологик фондтагы алынмаларга карата мөнәсәбәтен билгеләү кыен түгел. Галим тарафыннан кертеп җибәрелгән, активлаштырылган терминнарның телдә урнашып калуларының да төрлечә булуы күзәтелә. Ул терминологик берәмлекләрнең бер төркеме хәзерге тел белеме өлкәсендә:

а) үзгәрешсез кулланыла: *кушма җөмлә, сәбәп җөмлә, баш җөмлә, вакыт җөмлә, киләчәк заман, үткән заман, хәзерге заман, кушма исем, ясалма исем, ялгызлык исме, хәл фигыльләр, сыйфат дәрәҗәләре* һ.б. ;

б) тезмә термин составындагы ыру төшенчәне белдерүче компонент үзгәртелеп кулланыла: *йөкләтү бабы, кайтым бабы, барлык-юклык галәмәтләре, иркәләү-кечерәйтү галәмәтләре;*

в) төшенчәсе юкка чыгу аркасында кулланылыштан төшеп калган терминнар: *калым бабы, үтем бабы, оешкан җөмлә, исме масдар, фигыль масдар, шарт ярдәмлекләре.*

Г. Ибраһимовның татар теле лингвистик терминологиясен камилләштерү юнәлешендә алып барган гамәли эшчәнлеге  татарча яңа лингвистик терминнар иҗат итү, үз дәреслекләре аша аларны гамәлгә кертү, үзенә кадәр эшләнгән терминнарга анализ ясау һәм уңышлы дип саналганнарын активлаштыру, телдә кулланылып килгән гарәп-фарсы чыгышлы кайбер терминнарны, мәгънә – эчтәлекләрен конкретлаштырып, яңа термин составына кертеп  җибәрүдә чагылыш табуы күзәтелде.

Билгеле булганча, “ясалыш ысулы –сүзне динамик яктан, төзелеш тибы – статик яктан характерлый...” (Фасеев, 1969, 122 б.). Г. Ибраһимов ясалыш ысулы төзелеш калыбы белән үзара тыгыз бәйләнгән булуны яхшы аңлый һәм лингвистик терминнарны төрле ысуллар ярдәмендә ясый һәм төрле төзелеш калыпларына нигезләнә ( Ибраһимов. Фәнни истиляхлар).

Шулай итеп,  Г. Ибраһимовның  татар тел белеме терминнарын эшләүдә гамәли эшчәнлеге татарча яңа лингвистик терминнар иҗат итүдә, үз дәреслекләре аша аларны гамәлгә кертүдә, башка телче галимнәр тарафыннан тәкъдим ителгән терминнарны кулланылышка кертүдә, терминология мәсьәләсенә кагылышлы бәхәсләрдә катнашып (матбугат битләрендә), татар тел белеменең терминологик системасын оештыруда катнашуда чагылыш таба.

---


Вәлиди Җ. Галимҗан Ибраһимовның тел мәйданындагы хезмәтләре/ Г.Ибраһимов. Юбилей җыентыгы. Казан : Татиздат, 1928. Б. 131-142.

Ибраһимов Г. Истиляхлар һәйәтендән /Эшче,. - 1920, 20 декабрь, №126.

Ибраһимов Г. Фәнни истиляхлар / Аң.- 1913, № 24

Ибраһимов Г. Яңа әдәби татар теленең беренче баскычларында / К. Насыйри мәҗмугасы. – Казан, 1922. - Б.150 – 160.

Ибраһимов Г. Татар телен җиңеләйтү мәсьәләсен чишәргә кирәк / Кызыл татарстан, 1924, 14 сент.

Ибраһимов Г. Татар телен җиңеләйтү турында тезислар / Мәгариф, 1924, №3/4. –Б 169 -172.

Ибраһимов Г. Тел һәм атамалар турысында инструкция/ Кызыл Татарстан, 1926, 22 янв., № 28.

Ибраһимов Г. Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы / Г. Ибраһимов.

Т. 5 – Казан, 1978. – Б. 490-491.

Ибраһимов Г. Татар сарыфы / Г. Ибраһимов. – Казан, 2003.

Кириллова З.Н. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20- 30 нчы еллар)/ З.Н. Кириллова. – Казан: Мастер-Лайн, 2000.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле тарихы / В.Х.Хаков. – Казан, 1993. – Б. 313 323.

Хәерби. Татар сарыфы вә нәхүе / Йодыз, 1911, №751.